ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 39 10 февраль 2017 ел

**"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының" Урмандеево авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Советы
Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Урмандеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Юстиция органына Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр дәүләт теркәвеннән соң махсус мәгълүмати стендларда игълан ителергә тиеш.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге Советы Рәисе В.З.Николаев

Кушымта № 1
Аксубай муниципаль
районы Урмандеево авыл җирлеге
Советы карарына
10.02.2017ел № 39

**"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының" Урмандеево авыл җирлеге "муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"**

**1. 7 статьяны 15 пункт белән тулыландырырга) түбәндәге редакциядә:**

«15) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру

**2. 47 статьяның 2 өлеше түбәндәге редакциядә абзац белән тулыландырылсын:**

Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.